Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 103-1 08.10.2024 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 ноябрендәге 58-1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы

КАРА ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Советының 2018 елның 23 ноябрендәге 58-1 номерлы карары белән расланган (2019 елның 11 ноябрендәге 850-1 номерлы; 2020 елның 16 ноябрендәге 6-1 номерлы; 2021 елның 17 ноябрендәге 34-1 номерлы; 2023 елның 03 маендагы 70-1 номерлы үзгәрешләр белән) «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Алиев Александр Владимирович - Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге башлыгы;
- Вихлянский Александр Николаевич-Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге Советы депутаты;
- Сулейманова Марина Александровнавна - Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре.

3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 28.10.20240 елга кадәр түбәндәге адрес буенча кертелә: 422850, Татарстан Республикасы, Спас районы, Кызыл Бистә авылы, Мәктәп ур., 2 йорт, авторның Ф.И.О. һәм аның адресы һәм Kslob.Sps@tatar.ru электрон почтасына.

4. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектының гавами тыңлауларында катнашуга заявкалар Татарстан

Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2021 елның 08 июлендәге 22-2 номерлы карары белән расланган гавами тыңлаулар үткәрү Тәртибе нигезендә бирелә: 422850, Татарстан Республикасы, Спас районы, Кызыл Бистә авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт, шәхсән яисә почта аша ("Устава турында" конвертына тамга белән) заявкалар бирелә.

5.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар 29.10.2024 елга 10.00 сәгатьте Кызыл Бистә мәдәният йорты бинасында билгеләргә.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spassriy.tatarstan.ru һәм хокук мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча килүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эш төркеменә йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районының
Кызыл Бистә авыл җирлеге башлыгы А.В. Алиев

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә авыл җирлеге Советының 2024 елның 08 октябрендәге 103-1 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр

1. Уставның 5 статьясында:

1.1. 1 өлешнең 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

1.2. 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

2. Уставның 27 статьясында:

5 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл торак пунктының старостасы вәкаләтләре чоры җирлек уставы белән билгеләнә һәм биш ел тәшкил итә.»;

2.2 өлешнең икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 92 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2.3. 7 өлештә «җирлек уставы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Уставның 30 статьясында:

3.1. 6 өлешнең 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында «җирлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

3.2. 8 өлештә «әлеге Федераль закон белән» сүзләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга.

4. 33 статьяның 1 өлешендәге 32 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә рәсми мәгълүматны җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы учреждениесе;».

5. 40 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә::

"12) аның чит ил агенты статусын алуы.».

6. Уставның 49 статьясында:

6.1. 1 өлешнең 5 пунктына өченче абзац өстәргә:

- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала;";

6.2. 1 өлешнең 9 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

6.3. 49 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3. Җирлекнең башкарма комитеты Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган була.

Муниципаль контроль өлкәсендә җирлек башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) муниципаль берәмлек территориясендә муниципаль контроль оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) әлеге Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә бүтән вәкаләтләр.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә тикшерүләр оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

7. 63 статьяда:

7.1. 1 өлешнең 1 пунктында «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.;

7.2. 1 өлешнең 2 пунктында «йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру»сүзләренә алмаштырырга.;

7.3. 2 өлештә «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

8. 71 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"71 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе.

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек була торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып алар:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару https://pravo.tatarstan.ru (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында ФС77-60244 номерлы таныклык 2013 елның 17 декабрендә Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән) яисә вакытлы матбугат басмасында – «Новая жизнь» («Яңа тормыш») район газетасында (газета массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге законнарның үтәлешен күзәтү буенча федераль хезмәтнең Приволжский идарәсендә

теркәлгән, массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында 2007 елның 30 ноябрендәге 7-4762 номерлы ФС ПИ таныклыгы);

2) Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру: http:/ spasskiy.tatarstan.ru.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: Татарстан Республикасы, Спас районы, Кызыл Бистә авылы, Мәктәп урамы, 2нче йорт.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 эш көне эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр игълан ителә (рәсми басылып чыгудан тыш), Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.».